РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕВЛАШТАУСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
, Республика Татарстан, Сабинский район,
с.Евлаштау, ул. Ш.Бариева, д.23
тел. (84362) 46-8-49

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ЯВЛАШТАУ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
422075, Татарстан Республикасы,
Саба районы,
Явлаштау авылы, Ш.Бариев урамы,
23 йорт
тел. (84362) 46-8-49

e-mail: Evlash.Sab@tatar.ru

---

28.05.2020 №12

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы
Явлаштау авыл җирлегенең 2020 нче елга һәм
2021, 2022 нче елларның план чорына салым
чыгымнары исемлеген раслау

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге Башкарма комитетының «Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибен раслау турында»гы 01.04.2020 ел, №9 карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибенең 2 нче пункты нигезендә, Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлегенең 2020 елга һәм 2021, 2022 еллар план чорына салым чыгымнары исемлеген расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион «Интернет» челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Явлаштау авыл җирлек башлыгы Р.Х.Нуриев

Расланган
Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге Башкарма комитетының 28.05.2020 ел, №12 карары белән

**Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлегенең 2020 нче елга һәм 2021, 2022 нче елларның план чорына салым чыгымнары исемлеге**

| Муниципаль берәмлекнең салым ташламаларын, азат ителүне һәм салымнар буенча башка преференцияләрне билгели торган норматив хокукый акты | Муниципаль берәмлекнең норматив хокукый актларында билгеләнгән салым ташламаларын, азат ителүләрне һәм башка преференцияләрне бирү шартлары | Салым ташламалары, азат итү һәм башка преференцияләр каралган салым түләүчеләрнең максатчан категориясе | Муниципаль берәмлекнең салым ташламаларын, азат ителүне һәм салымнар буенча башка преференцияләрне билгели торган норматив хокукый актлары нигезләмәләренең үз көченә керү датасы | Муниципаль берәмлекнең норматив хокукый актлары белән салым ташламаларына, азат итүгә һәм салымнар буенча бүтән преференцияләргә бирелгән хокукның гамәлдә булу датасы | Муниципаль берәмлекнең норматив хокукый актлары белән бирелгән салым ташламаларының, азат ителүләренең һәм башка преференцияләрнең гамәлдә булу чоры | Муниципаль берәмлекнең норматив хокукый актларында билгеләнгән салым ташламаларының, азат ителүләренең һәм салымнар буенча башка преференцияләрнең гамәлдә булуын | Салым ташламаларының, азат ителүләренең һәм салымнар буенча башка преференцияләрнең исеме | Салым чыгымнарының максатчан категориясе (социаль ярдәм, стимуллаштыручы яисә техник ташлама) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | туктату датасы | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге Советы тарафыннан 2019 нчы елның 25 нче мартында кабул ителгән 9 нчы номерлы карар «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге Советының 2014 нче елның 14 нче ноябрендә кабул ителгән 27 нче номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге территориясендә физик затларның | Өч һәм аннан да күбрәк баласы булган күп балалы гаиләләрдә тәрбияләнүче 18 яшькә кадәрге балаларны физик затлар милкенә салым түләүдән азат итү | Өч һәм аннан күбрәк баласы булган күп балалы гаиләләрдә тәрбияләнүче 18 яшькә кадәрге балалар | 2018 елның 1 гыйнварыннан башлап | 2018 елның 1 гыйнварыннан башлап | Вакытсыз | Билгеләнмәгән | Тулы азат ителү | Халыкка социаль ярдәм |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| милкенә салым турында» гы карарына үзгәрешләр кертү турында» | | | | | | | | |
| Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге Советы тарафыннан 2019 нчы елның 26 нчы ноябрендә кабул ителгән 29 нчы номерлы карар «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Явлаштау авыл җирлеге территориясендә җир салымы турында» | Бөек Ватан сугышы ветераннарын һәм инвалидларын җир салымыннан азат итү | Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм инвалидлары | 2020 елның 1 гыйнварыннан башлап | 2020 елның 1 гыйнварыннан башлап | Вакытсыз | Билгеләнмәгән | Тулы азат ителү | Халыкка социаль ярдәм |